**“Татарстан Республикасы  Зеленодол муниципаль районы Советлар Союзы Герое В.Х.Хаҗиев исемендәге 7нче  мәктәп”**
**муниципаль бюджет  гомуми белем бирү учреждениесе**

**Секция исеме:**

**Нәсел-ыру тарихы (Минем нәсел шәҗәрәм).**

**Тема:**

“Тамырлары белән көчле безнең халык”


Башкарды: Вәлиуллина Алия Фәнис кызы
9нчы сыйныф укучысы

Укытучы:Хәмидова Зөлфирә Зәки кызы


**2022нче ел**

**Эчтәлек :**

1. Кереш_______________________________________________2-3 бит
2. Нәселне белү – бабаларыңа, телеңә хөрмәт ул.________ 3 -4 бит
3. Нәсел шәҗәрәсе _________________________________ 5-6бит
4. Йомгаклау___________________________________________7 бит
5. Кулланган әдәбият. ___________________________________8 бит
6. Кушымта____________________________________________9 бит

**Нәселне белү – бабаларыңа, телеңә хөрмәт ул.**

Хәтерләүдән курыкма син,
Үткәнеңне онытма син!
Бел син ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен.
Ни иккәнен, ни чәчкәнен,
Нинди уйлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.

Кереш

Шәҗәрә сүзе татар телендә нәсел-ыру тарихы дигән мәгънәдә файдаланыла. Шәҗәрә аркылы без ата-бабаларыбызның дәвамчысы булуыбызны да аңлыйбыз. Нәсел шәҗәрәсен белү - туган илгә, туган телгә мәхәббәт тәрбияләргә, туганнарга, кардәш-ыруга, хөрмәт һәм кайгыртучанлык күрсәтеп яшәргә кирәклеген искәртеп тора. Аның тамырлары гаилә тарихына килеп тоташса да, ул-шәхесләр тарихын гына түгел, ил,телебезнең тарихын да тирәнрәк белергә мөмкинлек бирә.«Һәр кеше үзенең җиде бабасын белергә тиеш, —дигәннәр борынгылар. — Шул вакытта гына кеше туган иленең, туган төбәгенең, үз халкының үткәнен яхшы белә». Ислам дине буенча, галим кешеләргә таләп тагын да югарырак: тугыз буыныңны белү шарт. Туган жир, туган туфрак, туган нигез, туган тел, туганнарыбыз... һәркем өчен изге һәм кадерле. Халкыбызда борын-борыннан җиде буын әби-бабаңа кадәр үз нәселеңнең буыннарын күңелдән белү һәм нәсел шәҗәрәләрен кәгазьгә теркәү гадәте булган. Шәҗәрәләр белү, язып бару — матур һәм борынгы гадәт. Әмма хәзерге вакытта бик сирәк гаиләләр генә үзләренең гаилә тарихы турында нәрсәдер белә. Кызганычка каршы, күпләр (әти - әниләре кебек үк) хәтта үз бабаларының әтиләре исемнәрен дә әйтә алмыйлар. Соңгы елларда генеалогия фәненә - нәсел тарихын өйрәнүгә - шәҗәрәләр төзүгә игътибар артты. Кайбер гаиләләр чын-чынлап үзләренең барлыгын аңларга: белеп булган барлык бабаларын эзләп табарга тырышалар. Татарлар арасында бүгенге көндә дә җиде, тугыз һәм аннан да артыграк бабаларын белүчеләр дә бар.

Бу – бик күп вакыт сорый торган, катлаулы, четерекле, шул ук вакытта кызыклы һәм бик саваплы эш. Шәҗәрә, билгеле булганча, нәсел агачы дигән сүз. Нәсел исә бер бабайдан килә торган кешеләр буыны. Шәҗәрә - нәсел-

ыруыңның кемнән башланып, ничек тармакланып китүен күрсәткән схема. Ул, башлыча, агач, сурәт рәвешендә була. Ата-баба агачның  кәүсәсе, якын туганнары - ботагы, аннан сабаклары, яфраклары китә.

### Тамырлары белән көчле безнең халык

Мин Яшел Үзән шәһәрендә туып-үссәм, яшәсәм дә әби- бабаларыбыз яшәгән, төп нигез булган, Апаска кайтып йөрергә яратам, җәйге каникулларымны да анда үткәрәм. Апас кешеләре үзенең күренекле  зур шәхесләре Сара Садыйкова, Фәхри Насретдинов, шагыйрь Шәүкәт Галиев һәм башка күп зыялы кешеләре белән горурлана ала. Мин Апас туган як музеенда шундый мәртәбәле,  Рәмис абый Ногманов  белән таныштым. Максатым: Рәмис абыйның шәҗәрәсен өйрәнү. Бу максаттан чыгып  шундый бурыч билгеләдем: моның өчен аның архив документларыннан файдаландым,туганнары белән сөйләшү, төрле мәгълүматлар белән танышу. Бигрәк тә, бабаларыбызның тормышы – көнкүрешләре, тормыш юлларын белү иде. Гаилә ядкарьләре белән кызыксындым, язып алдым. Рәмис абый. мәгариф отличнигы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, 2005 нче елдан Апас туган як музее директоры. Район тарихына, аның күренекле шәхесләре турында язган китаплар авторы. Тарихи мирасыбызны барлап, башкаларга җиткерә ул. Бөтен район халкы, укучылар ярдәме белән археология залларында тарихи кыйммәткә ия 10 меңнән артык табылдыклар туплаган,аларның тарихы,килеп чыгышы турында белешмәләр бирелгән.  Моңа кадәр билгеле булмаган районның зыялы кешеләре, шул исәптән, Апас төбәге белән бәйле булган татар халкының бөек шәхесләре  турында эзләнү эшләре алып бара., аларны барлау, шәҗәрәләрен эшләү  кебек зур эшләр дә башкара.

Хәтта чит илдә яшәгәннәр дә туганнары турында музейдан мәгълүматлар алып китү очраклары бар. Апас горурлыгы булган Сара Садыйкова, Фәхри Насретдинов,  Шәүкәт Галиев исемендәге музейлар ачу эшендә дә зур өлеш керткән кеше ул. Рәмис абый кебек шәхесләр турында сөйләгәндә, алар халкы, милләте өчен яши һәм эшли дип әйтәләр**.** Ул халкына, теленә ,туган ягына тугры гомере буе. Аның үз гаиләсенә, нәселенә, ата- бабаларына мөнәсәбәте, нәсел шәҗәрәсе  белән кызыксындым.

Туган өен белмәгән,
Туган авылын белерме?
Туган авылын белмәгән,

Туган илен белерме?

**Безнең нәсел шәҗәрәсенә килгәндә,** ул бик еракларга барып тоташа. Нәсел-нәсебен белеп, өйрәнеп, туганнарны, тамырларын барлаган, туплаган кеше ул. Ул үзенең әтисе, әнисе ягыннан да буыннар чылбырын төзегән, рәсемнәрен табып, хәтта төп нөсхәләрен, тирән, нык тамырлы, киң кәүсәле, күпботаклы купшы нәсел агачына урнаштырган. Нәтиҗәдә, киң тармаклы, күркәм ябалдашлы мәгърур нәсел шәҗәрәсе формалашкан. Туган жир, туган туфрак, туган нигез, туган тел, туганнарыбыз... һәркем өчен изге һәм кадерле. Ерак бабасы Габденнасыйр,(11) Минһаҗетдин, Гыйсаметдин. Алардан соң Хөснетдин, Ногман. Соңгы буыннар турында күп мәгълүматлар тупланган. Гыйсаметдинның уллары Хисаметдиннең һәм Хөснетдин (хаҗга да бара), Хисаметдинның улы Ногман. (Петр 1 нче крестьяннардан җан башыннан ясак(налог) җыюны кертә, ревизияләр үткәрә, ә ревизияләрдә кешеләрнең исемнәре генә бирелә.1815 нне елда 7нче ревизиядә(архивтан “ревизские сказки”1815-1817гг) ерак баба Габденнасыйр,(10) Минһаҗетдин(9) күрсәтелә. 1856 нчы енның 10 ревизия Гыйсаметдин(8) күрсәтелә,1897елгы перепись документларында Гыйсаметдинның уллары Хисаметдиннең һәм Хөснетдин язылган **7нче буын** 1916 нчы елдагы хуҗалыклар исемлегендә Хисаметдинның улы Ногман да бар.)

Алардан соң Хисаметдин. Аның нәсел чылбыры агачның уң ягын тулыладырып тора. Хисаметдиннең улы Хөснетдинның хаҗга да баруы мәгълүм. Телдән телгә сөйләнүләргә караганда, алар бик күренекле, дини, хөрмәткә лаек кешеләр булганнар. Аларның өйләрендә китаплар күп булуы һәм барлык бабаларның белемле, хезмәт сөючән булулары турында билгеле.

Ногман белән Таифә -бишенче буын, алар Факия, Минҗамал, Габдрахман, Фәйзрахман,Зәйнәп, Габдулла, Салихҗан исемле балалар үстергәннәр.(Нәсел агачының төп өлешен алып тора) шуларның берсе Госман бабай. Ул заманында күренекле укытучы Мозаффар Мөштәридән, Келәнче авылына барып, белем ала. Госман бабай белән Вәсимә әби - Рәмис абыйның әтисе белән әнисе.”Без бит 10 бала булганбыз,ә әтиебез, гаиләсе тернәкләнсен дип кем генә булып эшләмәгән. Беренчеләрдән булып шахтада тир түккән, сугышның ачысын-төчесен күргән, кайткач,5 ел колхоз рәисе,12ел бригадир, агротехник. Киләчәгегез нык булсын дисәгез эштән аерылмагыз дип киңәш, нәсихәт бирде безгә әти”,- дип әтисен олылап сөйли Рәмис абый.

- Әтиебез бик матур биюче, музыкага да һәвәс кеше иде, Һәрберебезнең беренче киңәшчесе-укытучысы әтиебез булды, ди. Чыннан да, алар турында,

алла аларга талант биргән, җырлы-моңлылылар, бар да нинди дә булса уен коралында уйный, авылның яме иделәр дип искә алалар.

Зәйтүнә апа иң олысы. Зәки абый белән дүрт бала үстерәләр,бар да югары белемле. Аларның очрашып өйләнүшеләре турында аерым ядкарьләр бар. Зәки абый Апас роносында инспектр булып эшли башлый. беркөнне кунакханәдә кунарга кала. Борнаш авылында колхоз рәисе Ногманов Госман ага белән бер номерга туры килә. Госман ага нәрсәдер караганда бер фотоны төшереп җибәрә. Зәки күтәреп ала да:

- Мин аңа өйләнәм, ди

Шуннан соң, бернигә карамый, Зәки абый Борнаш авылына мәктәп тикшерергә китә, дәресендә була, озатып йөри башлый. 1946 нчы елда өйләнешәләр. 59 ел бик тату гомер итәләр.Зәки абый Госман аганың иң яраткан кияве була. Рәмис абый бу хәтирәләрне бик җылы хисләр белән сөйләде. Ни дисәң дә, Зәйтүнә апасы беренче, ә ул- унынчы. Рәмис абый сер итеп кенә әйтте. Ул аның иң яраткан апасы булган, аның фотоларын саклый, аның җырлавын хәтта телефонында йөртә.Зәйтүнә Госман кызы 40 ел укытучы булып эшли. Россиянең мәгариф отличнигы.

Зәки абый 1941 нче елдан сугышка китеп,(партизан була)1946 нчы елда гына туган якларына кайта.

Бу нәселнең укымышлы булуын тагын бер нәрсә раслый: Вәсимә әбигә әнисеннән 1908 нче елда басылган китап кала, ул аны олы кызы Зәйтүнә әбигә язып калдыра, ә ул кызы Зөлфирә апага калдыра.Олы кызлар аны гаилә ядкаре, әби-бабаларыбызның истәлеге итеп буыннан - буынга саклап баралар.

Гыйлфан абый югары белемле, озак еллар Борнаш авылында маллар табибы(ветеринар) булып эшли(1930-1988). Галия апа белән өч бала үстерделәр,бар да югары белемле, уен коралларында уйныйлар, җырлы –биюле гаилә. Минневахит-(14.03-04.12.2006)КДАИХИда (хәзерге аграр университетта)экологиядә, туфрак белеменнән укыта.Хатыны Наилә белән 2 кыз үстерәләр.Надыйр-1932 нче елгы кече яшьтә вафат,.Вагыйз-1934-1949нчы елгы вакытсыз һәлак була. Гөлсинә-күренекле тегүче булып эшли, пенсиядә. Наилә апа -балалар табибәсе, мөселман табибә. Мөхәммәдия мәдрәсәсен бетергән. Балаларның физик, рухи яктан сәламәтлен саклау өлкәсендә ислам, әхлак белән тәрбияләү максатын күз алдында тотып эшли. Әтисе сугышка киткәндә Наилә апа 6 көнлек булып кала(1941нче ел 16нчы июнендә туган)Вәсимә әби 6 бала белән кала, эшли дә, 6 сын да, каты авырулардан, ачлыктан саклап кала гаҗәеп көчле бөек ана. Госман бабай һәр атакага Наилә

кызым өчен дип керә, исән-имин кайта, бөтен барлыгы белән эшкә чума. Госман бабайны ару-талуны белмәс, хезмәт сөючән, ачык йөзле, киң күңелле кеше буларак искә алалар. Сәләтле, көчле, укымышлы, күркәм,оста биюче иде, диләр.

Ринат-(24.08.1946-1.05.1993)-авыл һөнәри-техник училищесында укытучы, егетләр хоры оештыра, штангы күтәрү буенча алдынгы, җырчы.була Иң кечесе,10нчы бала, өченче буын- Рәмис абый. Тәгъзимә апа белән ике бала үстерәләр. абый кебек шәхесләр турында сөйләгәндә, алар халкы, милләте өчен яши һәм эшли дип әйтәләр. Ул халкына, теленә тугры гомере буе..

Гыйлемлелек, белемлелек, нәсел буенча килеп, балаларына да күчкән. Нәселендә нинди генә һөнәр ияләре юк. Икенче буын Марсель-укытучы,эшмәкәр, Әлбинә –табибә булып эшли. Алар нәсел җепләрен өзми, буыннан - буынга суытмый саклап баралар. Бу бары тик тырышлык, хезмәт сөючәнлек, бер – береңә хөрмәт нәтиҗәсе. Икенче буын балалары – укучылар.

Шәҗәрә белән танышканда, гаилә нәселе педагоглар-укытучылар династиясен саклап, дәвам итүчеләр дә икәне ачыкланды.Соңгы 4 буын химиклар эшен дәвам итә Минем әнием Талия ягыннан әби –бабаларыбызның нәсел җебе шушы Апас якларыннан башлануы белән горурланам мин. Минем нәсел җебем бик ераклардан шушы нәселгә тоташа да инде.

## Йомгаклау

Юкка гына шәҗәрә “агач” мәгънәсен аңлатмый. Тамырлары нык булган агач көчле җилләргә дә бирешмәгән кебек, үз асылын аңлаучылар, үз тамырларын тоючылар тормышта да югалып калмыйлар. Тамырлар ул - безнең бабаларыбыз, бабаларыбызның бабалары, гаилә традицияләре, гореф – гадәтләребез, бабаларыбызның данлыклы эш-гамәлләре, ниһаять, ул синең фамилияң, кушаматың, нигезең, халкың, Ватаның дип аңлыйм мин. Без нәселебездәге яхшы сыйфатларны тагы да үстерергә, киләчәк буынга тапшырырга тиеш. Буыннар чылбырын өзмичә, гаилә тарихына үзебезнең өлешне кертеп саклап бару безнең кулда, үзеңнән соң матур истәлек калдыру һәркемнең изге бурычы. Тарихи чынбарлык, өлкәннәр буыннан-буынга саклап килгән истәлекләр. Әнә шундый истәлекләрне бөртекләп җыеп, киләчәк буынга шәҗәрә аша тапшыру - әйбәт күренеш, халыкның бер матур традициясе ул. Шуларны булдыра алсак, нәселнең киләчәге өметле булачак. Шәҗәрәңне, ягъни нәсел агачыңны белү, эзләү - синең дә, минем дә, безнең дә игелекле бер эшебез булсын иде.

Рәмис абый белән сөйләшкәннән соң, үземнең дә этием, әнием, туганнарым ягыннан эзләнүләрне башлап, шәҗәрә төзүгә кызыксыну уятты. Мин дә үземнең нәсел шәҗәрәм белән кызыксынам. Әби-бабайларның ничек итеп көн иткәнен, ниләр белән шөгыльләнгәнен беләсем килде. Безнең нәсел шәҗәрәсенә килгәндә, ул бик еракларга барып тоташа. Минем максатым: эти, әни ягыннан да гаилә тарихын өйрәнү, шәҗәрә төзү. Моның өчен архив документларыннан файдаландым, туганнарыбыз белән сөйләшеп, төрле мәгълүматлар җыйдым. Бигрәк тә, бабаларыбызның тормышы –көнкүрешләре, тормыш юлларын белү иде. Гаилә ядкарьләре белән кызыксындым, язып алдым. Минем нәсел җебем бик ераклардан шушы нәселгә тоташа да инде.

Без, бүгенге буын бөреләре, йөзәрләгән, әби-бабаларыбыз нәселләрен дәвам итүебездән горурланып яшәргә, сәламәт яшәү рәвеше алып барып, үз чиратыбызда, сәламәт буын калдырырга тиешбез.

Кулланылган әдәбият :

1. Г. Рәхим Тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык. – Казан, 2008нче ел.

2. Марсель Әхмәтҗанов. Татар шәҗәрәләре.Казан.Татарстан китап нәшрияты, 2012 нче ел.

3. Новое в этнографических исследованиях татарского народа. – Казань, 1978нче ел.

4.Хәмзә Бәдертдинов, Борнаш иле,Казан-2010 нчы ел.


Илеңне бел, Телеңне бел, Бабаңны бел!!!